ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕНАЛИМСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЮГАРЫ НАЛИМ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**26.12.2018** Югары Налим ав. **№ 22**

**Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федраль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Югары Налим авыл җирлеге уставы белән, Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге Советының 2014 елның 12 февралендәге 114 номерлы «Гражданнарның үзара салымы турында» карары нигезендә, Югары Налим авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Югары Налим авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыюның әлеге тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокуки мәгълумати рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлекчәсендә урнаштырырга һәм халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

**Руководитель**
**Исполнительного комитета** **Ф.Н. Николаева**

Югары Налим
башкарма комитетының
2018 елның 26 декабрендәге
22 номерлы карарына
2 нче кушымта

Югары Налим авыл җирлеге
гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Әлеге Тәртип Югары Налим авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү 18 яшькә җиткән һәм Югары Налим авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гражданнар тарафыннан 15 февраленә кадәр, гражданнарның 1 нче группа инвалид категорияләреннән тыш, аларның җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашу-катнашмавына һәм аларның тавыш бирү барышында белдергән мөнәсәбәтләреннән бәйсез рәвештә түләнә.

3. Түбәндәге игътибарга лаеклы сәбәпләр булганда:

а) Вакытлыча хезмәткә яраксыз булу(6 айдан күбрәк)

б) Оешманың эшчәнлеге туктатылу сәбәпле һәм оешманың штатында хезмәткәрләр саны кыскарту сәбәпле эштән азат ителү.

гражданнарга гариза нигезендә ике айдан артык булмаган вакытка, түләү кертүне кичектереп тору рөхсәт ителергә мөмкин.

4. Бер тапкыр түләнә торган түләүне башкару турындагы белдерү кәгазе бланкы гражданнар игътибарына белдерү такталарына, «Татарстан Республикасы хокуки мәгълумати рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлекчәсендә кую, шулай ук имза куйдырып шәхсән тапшыру яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән җиткерелә.

Белдерү кәгазе үз эченә гражданнарның үзара салым акчаларын түләү реквизитларын, бер тапкыр түләнә торган акчаның тулысынча яки киметелгән күләмдәге суммасын, түләү вакытын алырга тиеш.

5. Гражданнардан алынган үзара салым акч алары Югары Налим авы л җирлеге лицевой счетына күчереләләр.

6. Түләүләрне башкару гражданнар тарафыннан акчаларны физик затлар теләге буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру, акчаларны почта аша күчерү (исәп-хисап оешмалары), Югары Налим авыл җирлеге башкарма комитеты аша күчерү хокукына ия булган оешма аша күчерү яки https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү хокукына ия булган оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

7. Түләү квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаган башка документлар түләү фактын раслау булып торалар.

8. Гражданнарның билгеләнгән срокта күчерелмәгән үзара салым акчалары закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Югары Налим
башкарма комитетының
2018 елның 26 декабрендәге
22 номерлы карарына
2 нче кушымта

Югары Налим башкарма комитеты
бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләү кертү турында
БЕЛДЕРҮ КӘГАЗЕ № __________

Түләүченең Ф.И.Ә.и. ______________________________________________

Адрес:_______________________________________________________

Нигезләмә ___________________________________________________
Сезгә көнгә кадәрге вакыт эчендә
____________________________________________чараны гамәлгә ашыру буенча сум күләмендә бер тапкыр түләнә торган түләүне түбәндәге реквизитларга күчерергә кирәк: Кабул итүче як банкы БИК _______________
Сч. №_________________________________
Кабул итеп алучы Сч. № _______________________________________
ИНН_________________________________________
КПП_________________________________________
КБК __________________________ОКАТО _______________________
Түләүнең билгеләнеше
_____________________________________________________________

Җитәкче ________________________________ ________________________
М.У.                    (имза)                              (тулысынча язылыш)

------------------------------**кисеп алу сызыгы**----------------------------------------------

(*муниципаль берәмлек исеме)* бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләүне ________сум күләмендә түләү турында № _____ белдерү кәгазе.
Түләүченең Ф.И.Ә.и. ___________________________________________________
Адрес: ______________________________________________________________

Кабул ителде «_____»20_______ел   _______________________________
                                                    (түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Белдерү кәгазе түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, түләү кәгазе өлеше (отрывной корешок) тутырыла һәм ___________________җирлеге башкарма комитетында кала.*